**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№1** **07.11.2024**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Александровка авыл җирлеге составына керүче,
Микулино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 7 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез, 2025 елда, Микулино авыл җирлеге Александровка торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентларда тыш, махсус хәрби операциягә юнәтелгән гаилә әгъзасы тупланган гаиләләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 175 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Торак пункт территориясен төзекләндерү (Александровка авылында юлларны кардан чистарту)

«ӘЙЕ » «ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 14 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 13 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 13 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

җыенда катнашучы 0 кеше «Юк» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Александровка авыл җирлеге составына керүче Микулино авылыдна узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: «Сез, 2025 елда, Александровка авыл җирлеге Микулино торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, махсус хәрби операциягә юнәтелгән гаилә әгъзасы тупланган гаиләләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 175 сум күләмендә

бер тапкыр түләүне киметеп,  үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган  түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- - Торак пункт территориясен төзекләндерү (Александровка авылында юлларны кардан чистарту) .

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Микулино авылы, Совет урамы, 74 нче йорт.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Микулино авыл җирлеге Башлыгы И.А.Такиулин